**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5254**
**09.08.2021**

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 елның 23 июнендәге 1219-р номерлы боерыгы, Башкарма комитетның 2021 елның 15 июлендәге 573 номерлы карары белән расланган 2021 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күргәзмә чаралары оештыру һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен күрсәтелгән муниципаль берәмлек бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе, Шәһәр Советының «2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2020 елның 15 декабрендәге 3/3 номерлы карары, Башкарма комитетның «2020-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 30 октябрендәге 5586 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибен 1 нче кушымтада каралганча;

2) күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү буенча комиссия составын 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында каралган чыгымнарны финанслауны 2021 елга шәһәр бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге/бүлекчәсе буенча каралган акчалар хисабына 25 458,432 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 9 августындагы
5254 номерлы карарына
1 нче кушымта

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр
күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга)
шәһәр бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә шәһәр бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Терминнар һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Бюджет кодексындагы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарындагы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 23 июнендәге 1219-р номерлы боерыгындагы, Башкарма комитетның 2021 елның 15 июлендәге 573 номерлы карары белән расланган 2021 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күргәзмә чаралары оештыру һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен күрсәтелгән муниципаль берәмлек бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендәге мәгънәләрдә кулланыла.

3. Субсидия бирү максаты булып, Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5586 номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасы нигезендә, күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (кайтару) тора.

Субсидия, күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында шартнамә (алга таба – субсидия бирү турында шартнамә) нигезендә, «Татарстан Республикасы

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан бирелә.

4. Сайлап алуда катнашучылар категориясе – күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәт күрсәткән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр. Катнашучыларны сайлап алу критерийлары – күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнар булу.

5. Субсидия алучыны билгеләү ысулы – тәкъдимнәр соратып алу.

6. Субсидия турында мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) урнаштырылган.

## 2 бүлек. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

7. Сайлап алу турында белдерү, әлеге карар чыккан көннән башлап өч эш көне эчендә, әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тарафыннан урнаштырыла.

8. Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәре (заявкалары) 2021 елның 10 августыннан башлап 8:00 дән 17:00 сәгатьләрдә 2021 елның 8 сентябре 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча яки шәһәр сайтында, шулай ук электрон почта адресы kancel.chelny@tatar.ru буенча Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә. Сайлап алу этаплары каралмаган.

9. Сайлап алуда катнашучылар сайлап алуны үткәрү планлаштырыла торган айдан алдагы айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

2) сайлап алуда катнашучының шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлары һәм бюджетыннан субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән, физик затларга субсидияләр алучылар тарафыннан товарлар кайтаруга (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле чыгымнарны каплау максатларында алынып бетмәгән керемнәрне, субсидияләрне кире кайтару максатларында бирелә торган субсидияләрдән тыш) бирү планлаштырыла торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге каршында акча йөкләмәләре буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычлары булмаска тиеш;

3) сайлап алуда катнашучы юридик затлар үзгәртеп оештыру, ликвидацияләнү, банкротлык процессында булмаска, аларга карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәгән булырга, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге туктатылмаган

булырга тиеш, ә сайлап алуда катнашучы шәхси эшмәкәрләр шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

4) дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучы юридик затның баш бухгалтеры турында, сайлап алуда катнашучылар булып торучы шәхси эшмәкәр турында һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне җитештерүче физик зат турында мәгълүматлар юк;

5) сайлап алуда катнашучылар салым салуның ташламалы салым режимын бирүче финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүматны ачыклау һәм бирүне күздә тотмаучы, теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше тулаем алганда 50 проценттан арткан чит ил юридик заты, шул исәптән Россия юридик заты булып торырга тиеш түгел;

6) сайлап алуда катнашучылар, әлеге тәртипкә туры китереп, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары (Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар) нигезендә, әлеге тәртиптә билгеләнгән максатларга шәһәр бюджетыннан субсидия алырга тиеш түгел.

10. Сайлап алуда катнашучы шәхсән яки ышанычлы зат аша Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

1) әлеге тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча тәкъдим (заявка);

2) гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

3) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

4) юридик затның оештыру документлары (устав; Россия Федерациясе законнары нигезендә оешкан юридик затның Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык; Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына язма кертү турында таныклык), физик затны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклык;

5) күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнар булуны раслаучы документлар (шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, башкарылган эшләр актлары, счет-фактуралар);

6) бухгалтерлык балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап һәм аларга кушымталар;

7) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә, Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә;

8) шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы

чыккан бурычлар, һәм шәһәр бюджетына башка срогы чыккан бурычлары булмау турында мәгълүматлар;

9) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар яки муниципаль хокукый актлар нигезендә шәһәр бюджетыннан акчалар алу (алмау) турында мәгълүмат;

10) салым органыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында мәгълүмат;

11) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан мәгълүматлар.

11. Сайлап алуда катнашучы Башкарма комитет адресына бер тәкъдим (заявка), шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (заявка), сайлап алуда катнашучы турында сайлап алу белән бәйле башка мәгълүмат чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын (физик зат өчен) җибәрә.

12. Сайлап алуда катнашучы үзенең яңа редакциядәге тәкъдимен (заявкасын) әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган башка документлар белән бергә аларны бирү срогы чыкканчы үзгәртергә яки кире алырга хокуклы.

Бу очракта сайлап алуда катнашучы Башкарма комитетка аның үзгәрүе яки кире алынуы турында белдерү кәгазе җибәрә, әгәр ул тәкъдимнәр (заявкалар) бирү срогы чыкканчы алынган булса, гамәлдә санала.

13. Сайлап алуда катнашучы үзгәрешләр кертелгән яңа редакциядәге тәкъдимен (заявкасын) һәм әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган документларны аларны бирү срогы чыкканчы Башкарма комитетка җибәрергә хокуклы.

Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәре (заявкалары) булган конвертларны ачу, тәкъдимнәрне соратып алу тәмамланган датадан соң икенче эш көнендә гамәлгә ашырыла һәм беркетмәгә теркәлә.

Сайлап алуда откан катнашучы булып, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән критерийларга, категорияләргә, шартларга туры килә торган тәкъдим (заявка) санала.

Берничә тәкъдимдә бер үк төрле шартлар булган очракта, алдан кергән тәкъдим откан дип танылга. Беркетмәгә тәкъдимнәр соратып алуда катнашучыларның тәкъдимнәрендә күрсәтелгән барлык шартлар, тәкъдимнәрне бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән мондый ахыргы тәкъдимнәргә тәртип номерларын бирү турындагы карар һәм тәкъдимнәр соратып алуда җиңүче шартлары теркәлә.

14. Сайлап алуда катнашучының тәкъдимен (заявкасын) кире кайтару өчен нигезләр:

1) тәкъдимдә (заявкада) сайлап алуда катнашучы вәкаләтлесенең имзасы булмау;

2) бер катнашучы тарафыннан, элек бирелгән тәкъдимнәре (заявкалары) кире алынмаган килеш, ике яки аннан күбрәк тәкъдим (заявка) бирелү.

Күрсәтелгән очракта бу катнашучыга мондый сайлап алуда катнашуга заявкаларның барысы да кире кайтарыла.

Сайлап алуда катнашучының тәкъдимен (заявкасын) тәкъдимнәрне (заявкаларны) карап тикшерү стадиясендә кире кагу өчен нигезләр:

1) сайлап алуда катнашучының әлеге тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

2) сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган тәкъдимнәрнең (заявкаларның) һәм документларның (документларны тапшыру турындагы таләп хокукый акт белән каралган очракта) сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә (заявкаларына) карата сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

3) сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турында мәгълүматның дөрес булмавы;

4) тәкъдим (заявка) сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим (заявка) бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелү.

15. Әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган документларны карап тикшерүнең гомуми срогы – сайлап алуда катнашучылардан тәкъдимнәр (заявкалар) кабул итү тәмамланган көннән башлап 10 эш көненнән артык түгел.

16. Башкарма комитетка әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган документлар кергән көнне Башкарма комитет Җитәкчесе аларны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрә.

17. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган документларны туплый һәм аларны карап тикшерү өчен, алар кергән көннән башлап бер эш көне эчендә, составы так, ләкин биш кешедән ким булмаган санда Башкарма комитет карары белән раслана торган, күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү буенча комиссиягә (алга таба - комиссия) җибәрә.

18. Комиссия эшчәнлегенең максаты булып тора:

1) сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) һәм әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган башка документларны сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире кайтару өчен нигезләрнең булуы яисә булмавы предметына карап тикшерү;

2) сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) һәм әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган башка документларны карап тикшерү һәм бәяләү стадиясендә сайлап алуда катнашучының тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире кагу өчен нигезләр булу яки булмау предметына карап тикшерү;

3) сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карап тикшерү һәм бәяләү, субсидия алучыларның шәһәр бюджетыннан

субсидияләр бирү өчен сайлап алуны үткәрү турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килүен (туры килмәвен) ачыклау.

19. Комиссия эшчәнлегенең бурычлары булып сайлап алуда катнашучыларның документларын карап тикшерү тора.

20. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

21. Комиссия әгъзалары хокуклы:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) комиссия рәисенә утырышны кичектерү турында тәкъдимнәр кертергә;

3) комиссиядә карап тикшерүгә чыгарылган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга;

4) карап тикшерүгә чыгарылган мәсьәлә буенча фикер белдерергә.

22. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиягә документлар кергән көннән башлап, өч эш көненнән дә соңга калмый, утырышны үткәрү датасын билгели;

2) комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

3) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны имзалый.

23. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын башкара.

24. Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиянең эшен алып бара;

2) комиссия утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;

3) комиссия әгъзаларына комиссия утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

4) әлеге тәртипкә 3 нче кушымтада каралган форма буенча, Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара һәм аны, утырыш үткәрү көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмый, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрә.

25. Комиссия эшчәнлегенең формасы булып, сайлап алуда катнашучылардан тәкъдимнәр (заявкалар) кабул итү тәмамланган көннән башлап ике эш көне эчендә үткәрелә торган утырыш тора.

26. Составының кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, комиссия утырышы тулы хокуклы санала.

Комиссия әгъзалары утырышта шәхсән катнаша. Комиссия әгъзасы утырышта булмаган очракта, ул карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы.

27. Сайлап алуда катнашучының билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында, субсидия бирүдән баш тарту турында комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, алар өчен комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, алар кабул

ителгән дип санала. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала. Комиссия карары комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

28. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның әлеге тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы булмаган күләмдә тапшырылу);

2) субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты ачыклану.

29. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы комиссия беркетмәсен алган көннән башлап өч эш көне эчендә, 4 нче кушымтада каралган форма буенча субсидия бирү турында шартнамә проектын яисә субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын (алга таба – карар проекты) әзерләүне һәм, имзалау өчен, аларны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне тәэмин итә.

30. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгынан карар проекты кергән көнне, Башкарма комитет Җитәкчесе аны имзалый һәм, теркәү һәм субсидия алучыга җибәрү өчен, Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрә.

31. Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

1) сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

2) тәкъдимнәре (заявкалары) карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

3) кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турында белдерүнең мондый тәкъдимнәр (заявкалар) туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп, тәкъдимнәре (заявкалары) кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

4) субсидия бирү турында шартнамә төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

Әлеге пунктта каралган мәгълүмат, беркетмә имзаланган көннән башлап өч эш көне эчендә шәһәр сайтында урнаштырыла.

32. Субсидия күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнар күләмендә, ләкин әлеге максатлар өчен агымдагы финанс елына шәһәр бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

Субсидия, субсидия бирү турында шартнамә һәм күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле барлыкка килгән чыгымнарны раслый торган документлар нигезендә бирелә.

Субсидияне финанслау чыганагы булып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 23 июнендәге 1219-р номерлы

боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр бюджетына кергән башка бюджетара трансферт тора.

Субсидия күләме Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2020 елның 15 декабрендәге 3/3 номерлы карары нигезендә билгеләнгән.

Субсидия бирү Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә казначылык ярдәме кагыйдәләре белән билгеләнгән казначылык ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

33. Субсидия, субсидия бирү турында шартнамә төзелгән көннән башлап унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучы тарафыннан ачылган һәм субсидия бирү турындагы шартнамәдә күрсәтелгән субсидия алучының исәп-хисап яки корреспондент счетына күчерелә.

34. Субсидия бирү нәтиҗәсе – күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплау.

35. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (файдалылыгы) буенча максатчан күрсәткеч булып түбәндәгеләр тора:

1) узган елның хисап чорына күргәзмә оешмалары эшчәнлегеннән бюджет керемен keremnәrne арттыру – биш процентка;

2) потенциаль максатчан клиентлар бирү, эшлекле элемтәләрне киңәйтү;

3) шартнамәләр, килешүләр төзү, инвесторлар җәлеп итү;

4) эш урыннарын саклап калу һәм (яки) арттыру һәм хезмәт өчен түләү фондын арттыру – алты процентка.

36. Субсидия алучы субсидияне күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү барышында барлыкка килгән чыгымнарны каплауга (шартнамәләр өчен түләүгә; әйләнештәге акчаларны тулыландыруга) юнәлдерә.

37. Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чарасы булып, субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылу ачыкланган очракта, шул исәптән бюджет акчаларын алучы буларак баш эш итүче һәм муниципаль финанс контроле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук әлеге тәртиптә билгеләнгән нәтиҗәләргә һәм күрсәткечләргә ирешмәгән очракта, шәһәр бюджетына субсидия акчаларын кире кайтару тора.

38. Субсидия алучы юридик затлар, шулай ук субсидияләр алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлаштыру эшләнмәләре сатып алганда (кайтарганда) гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук хокукый актлар белән билгеләнгән һәм әлеге акчаларны бирү максатларына ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алырга хокуклы түгел.

39. Субсидия алучылар, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгы финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы

булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру һәм җирле хакимият тарафыннан күрсәтелгән акчаларга ихтыяҗ булу яки, аларга ихтыяҗ булмаган очракта, күрсәтелгән акчаларны кире кайтару турында карар кабул иткәндә, мондый нигезләмәләрне хокукый акт белән (кирәк булганда) билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда килешүгә кертү мөмкинлегенә ия.

40. Субсидия алучылар, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар (аларның устав (склад) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (склад) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерцияле оешмалардан тыш) бюджет акчаларын алучы буларак баш эш итүче һәм муниципаль финанс контроле органы тарафыннан аларга карата субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга, шулай ук мондый нигезләмәләрне килешүгә кертү турында ризалыгын белдерәләр.

## 3 бүлек. Хисаплылыкка таләпләр һәм субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

41. Субсидия алучы, хисап елыннан соң килүче елның 31 декабренә кадәр срокта, субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында Башкарма комитет адресына хисап тапшыра.

42. Башкарма комитет субсидия бирү турындагы шартнамәдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.

43. Башкарма комитет исеменнән Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе һәм Башкарма комитетның финанс идарәсе, субсидия алучы тарафыннан субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык тапшырылган көннән башлап 9 эш көне эчендә, субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

44. Башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылу һәм (яки) әлеге тәртипнең 34 пунктында каралган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү ачыкланган очракта, өч эш көне эчендә субсидия алучыга кимчелек турында белдерү кәгазе һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләп җибәрелә.

Субсидия алучы, кимчелек турында белдерү кәгазен һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләпне алган көннән башлап 15 эш көне эчендә, субсидияне кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

45. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгы, хисап елыннан соң килүче финанс елының беренче 15 эш көнендә шәһәр бюджетына кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елы – субсидия алучы әлеге Тәртиптә каралган документларны Башкарма комитет адресына җибәргән ел.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Тәкъдимнәр соратып алу юлы белән, күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү өчен юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне сайлап алуны үткәрү турында белдерү

Башкарма комитетның __________ елның _______ номерлы карары белән расланган күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибе нигезендә Сезне күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджеттыннан 25 458,432 мең сум күләмендә субсидия бирү өчен тәкъдимнәр соратып алуда катнашырга чакырабыз.

Субсидия бирү максаты булып, Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5586 номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасы нигезендә, күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (кайтару) тора.

Сайлап алуда катнашучылар категориясе – күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәт күрсәткән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр.

Катнашучыларны сайлап алу критерийлары булып күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнар булу тора.

Сайлап алуда катнашучылар сайлап алуны үткәрү планлаштырыла торган айдан алдагы айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

2) сайлап алуда катнашучының шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлары һәм бюджетыннан субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидиялардән,

физик затларга субсидияләр алучылар тарафыннан товарлар кайтаруга (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле чыгымнарны каплау максатларында алынып бетмәгән керемнәрне, субсидияләрне кире кайтару максатларында бирелә торган субсидияләрдән тыш) бирү планлаштырыла торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге каршында акча йөкләмәләре буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычлары булмаска тиеш;

3) сайлап алуда катнашучы юридик затлар үзгәртеп оештыру, ликвидацияләнү, банкротлык процессында булмаска, аларга карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәгән булырга, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге туктатылмаган булырга тиеш, ә сайлап алуда катнашучы шәхси эшмәкәрләр шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

4) дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучы юридик затның баш бухгалтеры турында, сайлап алуда катнашучылар булып торучы шәхси эшмәкәр турында һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне җитештерүче физик зат турында мәгълүматлар юк;

5) сайлап алуда катнашучылар салым салуның ташламалы салым режимын бирүче финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүматны ачыклау һәм бирүне күздә тотмаучы, теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше тулаем алганда 50 проценттан арткан чит ил юридик заты, шул исәптән Россия юридик заты булып торырга тиеш түгел;

6) сайлап алуда катнашучылар, әлеге тәртипкә туры китереп, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары (Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар) нигезендә, әлеге тәртиптә билгеләнгән максатларга шәһәр бюджетыннан субсидия алырга тиеш түгел.

Сайлап алуда катнашучы шәхсән яки ышанычлы зат аша Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

1) күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 2 нче кушымтада каралган форма буенча тәкъдим (заявка);

2) гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

3) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

4) юридик затның оештыру документлары (устав; Россия Федерациясе законнары нигезендә оешкан юридик затның Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык; Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына язма кертү турында

таныклык), физик затны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклык;

5) күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнар булуны раслаучы документлар (шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, башкарылган эшләр актлары, счет-фактуралар);

6) бухгалтерлык балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап һәм аларга кушымталар;

7) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә, Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә;

8) шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлар, һәм шәһәр бюджетына башка срогы чыккан бурычлары булмау турында мәгълүматлар;

9) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар яки муниципаль хокукый актлар нигезендә шәһәр бюджетыннан акчалар алу (алмау) турында мәгълүмат;

10) салым органыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында мәгълүмат;

11) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан мәгълүматлар.

Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәре (заявкалары) ____________________8:00 сәгатьтән _______________________ 17:00 сәгатькә кадәр, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча яки шәһәр сайтында, шулай ук электрон почта адресы kancel.chelny@tatar.ru буенча Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) тәкъдимнәр соратып алуда катнашуга
ЗАЯВКА

1. Тәкъдимнәр соратып алуда катнашучы турында мәгълүмат:

| | |
|---|---|
| Исеме: | ______________________________ |
| Фирма исеме: | ______________________________ |
| Урнашу урыны: | ______________________________ |
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме: | ______________________________ |
| | ______________________________ |
| | ______________________________ |
| Почта адресы: | ______________________________ |
| Электрон почта адресы: | ______________________________ |
| Элемтә өчен телефон номеры: | ______________________________ |
| Салым түләүченең идентификация номеры: | ______________________________ |
| Сатуларда катнашучының гамәлгә куючыларының, коллегиаль башкарма орган әгъзаларының, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затның салым түләүче идентификация номеры: | ______________________________ |

2. ____________________________________ сайлап алуны үткәрү планлаштырыла торган айдан алдагы айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килә:

1) сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

2) сайлап алуда катнашучының шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлары һәм бюджетыннан субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелә торган субсидияләрдән, физик затларга субсидияләр алучылар тарафыннан товарлар кайтаруга (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле чыгымнарны каплау максатларында алынып бетмәгән керемнәрне, субсидияләрне кире кайтару максатларында бирелә торган субсидияләрдән тыш) бирү планлаштырыла торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге каршында акча йөкләмәләре буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычлары булмаска тиеш;

3) сайлап алуда катнашучы юридик затлар үзгәртеп оештыру, ликвидацияләнү, банкротлык процессында булмаска, аларга карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәгән булырга, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге туктатылмаган булырга тиеш, ә сайлап алуда катнашучы шәхси эшмәкәрләр шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

4) дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучы юридик затның баш бухгалтеры турында, сайлап алуда катнашучылар булып торучы шәхси эшмәкәр турында һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне җитештерүче физик зат турында мәгълүматлар юк;

5) сайлап алуда катнашучылар салым салуның ташламалы салым режимын бирүче финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүматны ачыклау һәм бирүне күздә тотмаучы, теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше тулаем алганда 50 процenttан арткан чит ил юридик заты, шул исәптән Россия юридик заты булып торырга тиеш түгел;

6) сайлап алуда катнашучылар, әлеге тәртипкә туры китереп, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары (Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар) нигезендә, әлеге тәртиптә билгеләнгән максатларга шәһәр бюджетыннан субсидия алырга тиеш түгел.

3. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан теркәлә торган мәгълүмат һәм документлар:

1) гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

3) юридик затның оештыру документлары (устав; Россия Федерациясе законнары нигезендә оешкан юридик затның Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык; Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына язма кертү турында таныклык), физик затны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклык;

4) күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнар булуны раслаучы документлар (шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, башкарылган эшләр актлары, счет-фактуралар);

5) бухгалтерлык балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап һәм аларга кушымталар;

6) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә, Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә;

7) шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлар, һәм шәһәр бюджетына башка срогы чыккан бурычлары булмау турында мәгълүматлар;

8) әлеге Белдерүдә күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар яки муниципаль хокукый актлар нигезендә шәһәр бюджетыннан акчалар алу (алмау) турында мәгълүмат;

9) салым органыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында мәгълүмат;

10) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан мәгълүматлар.

___________________ «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (заявка), сайлап алуда катнашучы турында сайлап алу белән бәйле башка мәгълүмат чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын (физик зат өчен) белдерә.

Вәкаләтле затның
вазыйфасы имза имзаның расшифровкасы
М.У.

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Тәкъдимнәр соратып алу БЕРКЕТМӘСЕ №_________

____________________________ Яр Чаллы шәһәре

1. Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны:

2. Катнашучы комиссия әгъзалары:

| Вазыйфаи затның Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|
| | |

Карар кабул итү өчен кворум бар.

3. Түбәндәге сайлап алуда катнашучылардан тәкъдимнәр (заявкалар) керде:

1)_____________________________________________________________;

2)_____________________________________________________________.

4. Кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый тәкъдимнәр (заявкалар) туры килми торган сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен күрсәтеп, тәкъдимнәре (заявкалары) кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат:

| Сайлап алуда катнашучының исеме | Тәкъдимне (заявканы) кире кагу нигезләре |
|---|---|
| | |
| | |

5. Субсидия бирү турында шартнамә төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме:

_________________________________________________________________

Комиссия әгъзаларының имзалары:

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
4 нче кушымта

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга)
Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында
шартнамә №________

Яр Чаллы шәһәре «____» __________ 2021

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, алга таба «Вәкаләтле орган» дип аталучы, бер яктан, ________________ нигезендә эш итүче ______________ исеменнән һәм икенче яктан ______________, алга таба «Алучы» дип аталучы, ________нигезендә эш итүче ________________ исеменнән, бергә «Яклар» дип аталучылар, күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) шәһәр бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссиянең ___________ № _____ беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Шартнамәне төзеделәр:

1. Шартнамә предметы

1.1. Вәкаләтле орган Алучыга _________________________ күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан ____________________________ (_______________) сум күләмендә субсидия бирә.

Алучы тарафыннан субсидия ___________________________ өчен җибәрелә.

1.2. Бирелә торган субсидия максатчан характерга ия һәм ул әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында каралмаган максатлар өчен файдаланыла алмый.

1.3. Субсидия 2021 елга шәһәр бюджетында каралган лимитлар чикләрендә бирелә.

1.4. Шәһәр бюджетыннан субсидия бирүне җайга сала торган хокукый актлар:

1) Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2020 елның 15 декабрендәге 3/3 номерлы карары;

2) Башкарма комитетның ______________ елның _____ номерлы карары.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Вәкаләтле орган түбәндәге хокукларга ия:

2.1.1. әлеге Шартнамә буенча бирелә торган субсидияне Алучы тарафыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануга контрольне гамәлгә ашырырга;

2.1.2. әлеге Шартнамәне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча Алучыдан өстәмә мәгълүмат сорарга һәм алырга.

2.2. Вәкаләтле орган түбәндәгеләргә бурычлы:

2.2.1. әлеге Шартнамәдә каралган күләмдә, тәртиптә һәм шартларда Алучыга субсидия күчерергә;

2.2.2. субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозган очракта, субсидияне кире кайтару турында карар кабул итәргә.

2.3. Алучы түбәндәгеләргә хокуклы:

2.2.1. субсидия бирү шартларын үтәгәндә, әлеге Шартнамә төзелгән көннән башлап ун эш көне эчендә, шәһәр бюджеты акчалары хисабына аны алу хокукына ия.;

2.3.2. әлеге Шартнамәдә каралган максатлар өчен хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашырырга.

2.4. Алучы түбәндәгеләргә бурычлы:

2.4.1. Башкарма комитетның ___________ елның _______ номерлы карарында каралган субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешергә.

2.4.2. әлеге Шартнамәгә кушымтада каралган форма буенча, субсидияне файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләре турында хисапны нигезләүче документлар белән Вәкаләтле органга тапшырырга;

2.4.3. әлеге Шартнамә буенча бирелә торган субсидиянең максатчан файдаланылуын тәэмин итәргә;

2.4.4. алучы тарафыннан Башкарма комитетның ________ елның _______ номерлы карарында һәм әлеге Шартнамәдә каралган субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылган очракта, субсидияне шәһәр бюджеты кеременә кире кайтарырга.

3. Субсидия бирү тәртибе һәм шартлары, хисаплылыкка таләпләр

3.1. Субсидия әлеге Шартнамә нигезендә, субсидия бирү турында шартнамә төзелгән көннән башлап унынчы эш көненнән дә соңга калмый, әлеге Шартнамәнең 8 бүлегендә күрсәтелгән счетка күчерелә.

3.2. Алучының субсидияне файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүе турындагы хисаплылыкка таләпләр булып хисаплылыкта күрсәтелгән мәгълүматларның тулылыгы, дөреслеге һәм тикшерә алырлык булуы тора.

3.3. Алучы хисап елыннан соң килгән елның 1 февраленә кадәр срокта, әлеге Шартнамәгә кушымтада каралган форма буенча субсидияне файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүе турында еллык хисапны Вәкаләтле орган адресына тапшыра.

3.4. Әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән субсидия бирүнең мәҗбүри шартлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Алучының һәм әлеге Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән Шартнамәләр (килешенүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып саналган затларның (аларның устав (склад) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (склад) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерцияле оешмалардан тыш) субсидия биргән бюджет акчаларын төп бүлүче (бүлүче) һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан аларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

2) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлаштыру эшләнмәләре сатып алганда гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, күрсәтелгән юридик затларга субсидия бирүне җайга сала торган норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән һәм әлеге акчаларны бирү максатларына ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алуны тыю.

## 4. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы

4.1. Әлеге Шартнамә Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм Якларның үз йөкләмәләрен тулысынча үтәүләренә кадәр гамәлдә була.

4.2. Субсидия алучы тарафыннан субсидия максатчан файдаланылмау сәбәпле, шәһәр бюджетына кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасы шәһәр бюджетына күчерелгән көннән башлап өч эш көне эчендә әлеге Шартнамә Вәкаләтле орган тарафыннан срогыннан алда өзелергә мөмкин.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Алучы әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән субсидиядән максатчан файдаланмган очракта, Алучы бюджет акчаларын

максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралганча җаваплы.

5.2. Башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылу һәм (яки) нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү ачыкланган очракта, өч эш көне эчендә Алучыга бозу очраклары турында белдерү кәгазе һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләп җибәрелә.

5.3. Алучы, бозу очраклары турында белдерү кәгазен һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләпне алган көннән башлап 15 эш көне эчендә субсидияне кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

## 6. Бәхәсләрне карап тикшерү тәртибе

6.1. Әлеге Шартнамә Якларның килешенүе буенча өзелергә мөмкин.

6.2. Әлеге Шартнамә буенча барлык фикер каршылыклары һәм бәхәсләр Яклар арасында сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

6.3. Барлыкка килгән бәхәсне сөйләшүләр юлы белән җайга салу мөмкинлеге булмаган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә бәхәс Татарстан Республикасы Арбитраж Судында карап тикшерелергә тиеш.

## 7. Башка шартлар

7.1. Әлеге Шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә рәсмиләштерелгән, вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланган һәм ике Якның да мөһерләре белән расланган булса, гамәлдә дип саналалар.

7.2. Әлеге шартнамәгә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып баш эш итүчегә, бюджет акчаларын алучы буларак, субсидия бирү өчен бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитларын киметү тора.

7.3. Әлеге Шартнамә бертигез юридик көчкә ия дүрт нөсхәдә төзелде: ике нөсхә – Вәкаләтле органга, бер нөсхә – Алучыга, бер нөсхә – Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Территориаль бүлегенә.

7.4. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калганы, хисап елыннан соң килүче финанс елының беренче 15 эш көне эчендә шәһәр бюджетына кайтарылырга тиеш.

## 8. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга) Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында «__» __________ № _____ шартнамәгә кушымта

Субсидсиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында
хисап

| № т/б | Субсидия алучының исеме | Нәтиҗәлелек күрсәткеченең исеме | Хисап датасына нәтиҗәлелекнең фактик күрсәткече | Субсидиядән файдалану күрсәткече | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

Кушымта: раслаучы документларның күчермәләре.

Вәкаләтле затның
вазыйфасы имза имзаның расшифровкасы

Башкаручы ___________________ _____________ ____________________________
(имза) (вазыйфа) (имзаның расшифровкасы)

М.У.

Башкарма комитетның
2021 елның 9 августындагы
5254 номерлы карарына
2 нче кушымта

Күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә
бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (кайтаруга)
шәһәр бюджетыннан субсидия бирү буенча
комиссия

| Вазыйфаи затның Ф.И.А.и. | вазыйфасы |
|---|---|
| Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| Кропотова Наталия Анатольевна | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| комиссия әгъзалары: | |
| Мулюкова Светлана Рафаиль кызы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| Гыйләҗева Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| Сәгъдиев Айрат Сәгыйть улы | комиссия секретаре, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү бүлеге башлыгы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева